КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 ноябрь г.Казань № 964

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан, су асты суларыннан файдалану, шулай ук җир асты корылмаларын төзү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 февраль, 171 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан, су асты суларыннан файдалану, шулай ук җир асты корылмаларын төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан, су асты суларыннан файдалану, шулай ук җир асты корылмаларын төзү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 февраль, 171 нче карары белән (Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 июль, 646 нчы, 2014 ел, 22 май, 347 нче, 2015 ел, 14 август, 589 нчы, 2016 ел, 23 июнь, 434 нче, 2021 ел, 21 апрель, 266 нчы, 2022 ел, 27 апрель, 398 нче, 2023 ел, 10 август, 967 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан, су асты суларыннан файдалану, шулай ук җир асты корылмаларын төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның бишенче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләрне рекультивацияләү һәм консервацияләү турында» 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләрне рекультивацияләү һәм консервацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 29 маендагы 781 номерлы карары» сүзләренә алыштырырга;

9 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләрне рекультивацияләү һәм консервацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 29 маендагы 781 номерлы карары нигезендә, гомумтаралган файдалы казылмалар куллану яисә җир асты корылмасы төзелеше туктатылганнан соң, ул расланган көннән алып 15 көн эчендә бозылган җир участокларын рекультивацияләү буенча эшләрне тәма актын Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына тапшырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин